СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЮГАРЫ ОСЛАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

21.01.2020 с. Верхний Услон № 64-318

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге территориясендә физик затларның мөлкәтенә салым турында» Югары Ослан авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендә кабул ителгән 48-254нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясы нигезендә Югары Ослан районы прокурорының 2009 елның 25 декабрендә кабул ителгән 02-07-02нче номерлы протестын карап тикшергәч,

Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге территориясендә физик затларның мөлкәтенә салым турында» Югары Ослан авыл җирлеге Советының 2014 елның 10 ноябрендә кабул ителгән 52-253нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы 1 пунктчасының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яки төзелеш»;

1.2. 2 пунктның 2 пунктчасында «фатирлар» сүзеннән соң «фатирлар өлешләре» сүзләрен өстәргә, «бүлмәләр» сүзеннән соң «бүлмәләр өлешләре» сүзләрен өстәргә;

1.3. 2 пунктның 3 пунктчасында «торак йортлар» сүзеннән соң «торак йортларның бер өлеше» сүзләрен өстәргә.

2. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» карар текстын яңа редакциядә расларга (1нче кушымта)

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге
Башлыгы М.Г.Зиатдинов

Югары Ослан авыл җирлеге Советының
2020 елның 21 гыйнварындагы
64-318нче номерлы карарына
1нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Югары Ослан авыл җирлеге территориядә физик затлар мөлкәтенә салым турында

1. Югары Ослан авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә мәҗбүри түләнергә тиешле салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

1) 0,1 процент:

гаражлар һәм машина-урын;

мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яки төзелшкә карата»;

2) 0,2 процент:

Фатир, фатирларның бер өлеше;

бүлмә, бүлмәләрнең бер өлешенә карата;

3) 0,3 процент:

торак йортлар, торак йортларның бер өлешләренең;

әгәр мондый объектларның проектланучы билгеләнеше торак йорт булса, төзелеп бетмәгән төзелеш объектлары;

составына бер генә торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплексларга карата;

4) 2 процент:

аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата;

5) 0,5 процент башка салым салу объектларына карата;

6) 2015 елда – 1,5 процент, 2016 елда-1,8 процент, 2017 елда-2 процент, алдагы елларда-Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына; Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясындагы 10 пунктындагы икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата.

3. Ике фатирдан торган күп фатирлы торак йорттагы фатир милекчеләренә ташламаны әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метры кадастр бәясенең процент өлеше буларак билгеләнә торган салым суммасын киметү рәвешендә билгеләргә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламаларның суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукында пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектә катнашучыларның һәркайсы өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Бу очракта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы аны исәпкә алмыйча исәпләнгән салым суммасыннан артып китә алмый.

Совет Рәисе
ТР, Югары Ослан муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге Башлыгы М.Г.Зиатдинов